**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

КАРАР
2020 елның «30» октябреннән

КАРАР
№ 1

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81, 22 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 10.00 да Тынычлык урамындагы 73-нче номерлы йорт янында Тынычлык урамы буенча 71-91 нче номерлы йортларда һәм Дуслык урамы буенча 49-61 нче номерлы йортларда яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 12.00 дә Яшьләр урамындагы 100-нче номерлы йортта урнашкан Тубылгы Тау мәктәбендә Тынычлык урамы буенча 1-70 нче номерлы йортларда һәм Дуслык урамы буенча 1-45 нче номерлы яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 14:00 тә Тубылгы Тау мәдәният йортында (Яшьләр ур. 94а йорт) Яшьләр урамы буенча 1-88-нче номерлы йортларда яшәүчеләр өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Тубылгы Тау халкы исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераннары, сугыш ветераннарының тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, I группа инвалид, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан башка 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны

Тубылгы Тау территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Яшьләр урамы, Тынычлык урамы, Дуслык урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эш өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- юлларны грейдлау (килешү буенча түләү);

- уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф. Исмагилов